Тапшырылган материалларны өйрәнеп, эштә катнашучы яклар һәм затларның чыгышларын тыңлагач, Татарстан Республикасы Конституция суды гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның әлеге өлештәге дәлилләре белән түбәндәге нигезләр буенча килешә алмый.

«Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итү моментына гамәлдә булган 2014 елның 25 декабрендәге редакциясендә) 5 статьясы нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару көне булып «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналында «рәсми рәвештә бастырып чыгарыла» тамгасы белән тулы текстның беренче мәҗбүри публикациясе яисә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) яки «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала.

«Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары тулы күләмдә 2015 елның 16 мартында «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарылган, әлеге портал, мөрәҗәгать итүче дәлилләренә каршы, «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталары белән беррәттән бертигез рәсми рәвештә бастырып чыгару чыганагы булып тора.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының югарыда китерелгән нормалары мәгънәсе буенча дәгъвалана торган карарның рәсми рәвештә басылып чыгу көне булып 2015 елның 16 марты санала.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы белән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары рәсми басылып чыккан көннәреннән соң 10 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр актларның үзләрендә аларның бүтән, соңрак, үз көченә керү вакыты билгеләнгән булмаса (6 статья), дип билгеләнгәнгә игътибар итәргә тиешле дип саный. Әлеге

тәртипне үтәү мәҗбүри, чөнки ул закон таләпләренә нигезләнгән мөһим процессуаль элемент булып тора. Моңа Россия Федерациясе Конституция Суды да күрсәтә, аның хокукый позициясе буенча федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларының легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм игълан итү тәртибен үтәүне дә күздә тота; гамәлдәге хокукый җайга салу системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект, кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне кертә (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы Карар). Күрсәтелгән хокукый позиция Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларына карата да тулысынча кулланылырга мөмкин.

Димәк, дәгъвалана торган карар 2015 елның 26 мартыннан иртәрәк үз көченә кермәскә тиеш иде. Шулай да әлеге карарның 5 пункты белән аның 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүе каралган. Шулай итеп, дәгъвалана торган карарның үз көченә керү вакытын аның рәсми рәвештә басылып чыгу көненнән иртәрәк билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актның законда билгеләнгән үз көченә керү тәртибен бозган.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясы белән үзара бәйләнештә 103 статьясы нигезендә дәгъвалана торган нормаларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүгә тикшерү чикләре шул исәптән аларны гамәлгә кертү тәртибе буенча билгеләнә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карала торган карарын аның үз көченә керү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануның 2015 елның 1 гыйнварыннан 26 мартына кадәрге чорда гражданнарга күрсәтелгән социаль хезмәтләрнең законлылыгын шик астына куярга мөмкинлек бирә алу фактын да игътибарга ала. Мондый нәтиҗә конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде, алар Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы буенча Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен яклаудан, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Бәян ителгәннәр нигезендә, шулай ук гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның шикаяте бирелү моментына «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында

социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карарының законда билгеләнгән тәртиптә үз көченә кергән булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә аның үз көченә керү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәвен танудан тыелып кала. Шулай да кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларның, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан чыгарыла торганнарның үз көченә керү тәртибенә куелган закон таләбен үтәү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең барлык органнары өчен мәҗбүри, ә әлеге таләпне бозу — рөхсәт ителми.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Мөрәҗәгать итүче килешмәгән социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү ешлыгы инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә ике елга 1 тапкыр тәшкил итә дигән норма Тәртипнең V бүлегенең 5.4 бүлекчәсендәге 5.4.2 пунктының (алга таба — 5.4.2 пункт) икенче абзацында бар. Социаль хезмәтләрне бушлай яки түләүле яисә өлешчә түләүле нигездә күрсәтү кагыйдәләре Тәртипнең V бүлегенең 5.2 бүлекчәсендәге 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктлары (алга таба — 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктлар) белән билгеләнгән, ә социаль хезмәтләрне шартнамә нигезендә күрсәтү — Тәртипнең V бүлегенең 5.3 бүлекчәсендәге 5.3.1 пункты (алга таба — 5.3.1 пункт) белән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук 5.3.1 пунктының хокукый нигезләмәләре әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъект-

ларының уртак карамагында, шуңа күрә Татарстан Республикасы әлеге өлкәдә хокукый җайга салуны федераль законнар нигезендә һәм аның законнары, башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килмәсә генә, гамәлгә ашырырга хокуклы (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт хакимиятенең федераль органнары вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели (1 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты). Шул ук вакытта аталган Федераль законның 8 статьясы нигезендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау керә (10 пункт).

Күрсәтелгән Федераль законны үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтләренә керә (4 статьяның 8 пункты).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган карарны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы белән үзара бәйләнештә 54 статьясының беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасында һәркем, сәламәтлек саклауның дәүләт һәм бүтән учреждениеләре законда билгеләнгән тәртиптә күрсәтә тор-

ган медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы (52 статья, беренче өлеш) дип игълан итә. Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 39 (1 өлеш) һәм 41 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1996 елның 3 маендагы Европа социаль хартиясенең (яңадан каралган) 15 статьясындагы якларның, аерым алганда, инвалидларга тулы социаль интеграциягә һәм җәмгыять тормышында катнашуга хокукны нәтиҗәле гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итү бурычын күздә тота торган нигезләмәләренә, шулай ук Инвалидлар хокуклары турындагы конвенциянең (БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан 2006 елның 13 декабрендә кабул ителгән, 2012 елның 3 маендагы 46-ФЗ номерлы Федераль закон белән ратификацияләнгән) инвалидларның лаеклы тормыш дәрәҗәсенә һәм социаль яклауга хокукын шулай ук таный торган 28 статьясына туры килеп торалар.

Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау өлкәсендә максаты инвалидларга Россия Федерациясе Конституциясе белән каралган граждан, икътисади, сәяси һәм башка хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыруда башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләрне шулай ук халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә тәэмин итү булган дәүләт сәясәтен «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон билгели.

Күрсәтелгән Федераль законның 9 статьясындагы беренче өлеше нигезендә инвалидларны тернәкләндерү — инвалидларның көнкүреш, иҗтимагый, һөнәри һәм башка эшчәнлеккә сәләтләрен тулысынча яисә өлешчә торгызу системасы һәм процессы ул. Әлеге статьяның икенче өлешендәге дүртенче абзацына күрә социомәдәни тернәкләндерү инвалидларны тернәкләндерүнең төп юнәлешләренә карый. Үзенең асылы буенча социомәдәни тернәкләндерү инвалидларга массакүләм мәдәни-ял итү чараларында һәм социомәдәни эшчәнлектә тулысынча катнашу өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Карала торган Федераль законның 10 статьясындагы икенче өлешен үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 декабрендәге 2347-р номерлы күрсәтмәсе белән инвалидка күрсәтелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм хезмәтләрнең федераль исемлеге расланган, анда тернәкләндерү чараларына торгызу терапиясе, реконструктив хирургия, шифаханә-курорт дәвалавы, протезлау һәм ортезлау, колак аппаратларын бирү, инвалидларның һөнәри ориентацияләнүен тәэмин итү керә. Тернәкләндерү чараларының әлеге федераль исемлегенә инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү керми, чөнки ул инвалидларга аларның коммуникатив потенциалын күтәрү максатында күрсәтелә торган хезмәт булып тора һәм үзенең хокукый табигате буенча Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2014 елның 24 ноябрендәге 1236 номерлы карары белән расланган Социаль хезмәтләр төрләре буенча социаль хезмәтләрнең якынча исемлегенең 7 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә карый. Тиңдәш нигезләмә «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында бар (8 статьяның 7 өлешендәге 2 пункты).

Социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә карата таләпләр «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон белән регламентлаштырылган, аның нигезендә әлеге тәртип социаль хезмәт күрсәтү формалары (өйдә, ярымстационар яки стационар формаларында), социаль хезмәтләр төрләре буенча билгеләнә һәм үз эченә социаль хезмәт күрсәтү стандартын ала (27 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты). Үз чиратында социаль хезмәт күрсәтү стандарты шул исәптән аны күрсәтү срокларын (ешлыгын) үз эченә ала (3 статьяның 5 пункты, 27 статьяның 3 өлешендәге 2 пункты).

Социаль хезмәт күрсәтүнең формасы һәм төреннән чыгып социаль хезмәтләр күрсәтүнең конкрет ешлыгы федераль законнарда билгеләнмәгән. Шуңа күрә социаль хезмәтләр күрсәтелүгә ихтыяҗны һәм гомумән Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә дәгъвалана торган Тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге ешлыгын билгеләгән: халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә — елга 2 тапкыр, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә — ике елга 1 тапкыр, ә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә буш урыннар булганда (чират булмаганда) — елга 1 тапкыр (5.4.2 пунктның икенче абзацы).

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норманы Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне җайга сала торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре белән системалы берлектә карарга кирәк, чөнки гамәлдәге законнар белән социаль-тернәкләндерү чараларын социаль хезмәт күрсәтүнең шулай ук башка формаларында күрсәтү мөмкинлеге каралган. Шулай, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең III бүлегенең 3.4 бүлекчәсендәге 3.4.2 пунктының 2 абзацы нигезендә социаль хезмәтләр гражданнарга шулай ук социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалид-

ларны тернәкләндерү үзәкләрендә елга 2 тапкыр ешлык белән күрсәтелергә мөмкин.

Шулай итеп, дәгъвалана торган нигезләмәләр, мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә каршы, гражданнарның социаль хезмәтләрне үзләренең сайлавы буенча һәм социаль хезмәт күрсәтүнең формасына (стационар яки ярымстационар) карап, төрле ешлык белән, шул исәптән аларның тернәкләндерүнең индивидуаль программасында каралган күләмдә алырга хокукларын чикләми.

Мондый хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы нигезендә халыкны социаль яклау гарантияләрен тәэмин итәргә бурычлы социаль хокукый дәүләт максатлары белән яраша. Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә күрсәтелә торган социаль яклауның конкрет ысулларын һәм күләмен билгеләми — әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының өстенлеге булып тора, ул, хокукый җайга салуны башкарганда социаль өлкәдә конституциячел гарантияләрне гамәлгә ашырып, социаль яклау чараларын билгеләгәндә, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлаганда һәм күрсәтелү шартларын регламентлаштырганда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә (2016 елның 13 апрелендәге 11-П номерлы Карар, 2015 елның 9 июнендәге 1230-О номерлы Билгеләмә).

Димәк, Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү ешлыгын ике елга 1 тапкыр итеп билгели торган нигезләмәләре гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзләренең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча дәүләт тарафыннан гражданнарның социаль яклауга хокукларын тормышка ашыру чараларын тәэмин итүгә юнәлгән механизмның бер элементы булып тора, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган итеп карала алмыйлар.

4. Социаль хезмәтләр, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешеннән аңлашылганча, гражданга социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче, граждан яки аның законлы вәкиле арасында төзелә торган шартнамә нигезендә күрсәтелә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәнең әһәмиятле шарты булып шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтү кыйммәте тора, әгәр алар түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелсә (17 статьяның 2 өлеше). Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар Тәртипнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 5.3.1 пунктында бар.

Югарыда аталган Федераль закон белән социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган гражданнар категорияләре билгеләнгән (31 статьяның 1 өлеше). Шул ук вакытта күрсәтелгән статьяның 3 өлешендә Россия Федерациясе субъектларының норматив хо-

кукый актлары белән социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган гражданнарның башка категорияләре каралырга мөмкин дип билгеләнгән.

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгәнчә, әгәр мөрәҗәгать итү датасына социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә бер кешегә уртача исәпләнгән кереме социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашырган өчен бер кешегә уртача исәпләнгән кеременең чик күләменнән аз яисә чик күләменә тигез булса, өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар һәм стационар формаларында социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган гражданнарның башка категорияләре каралырга мөмкин дип күрсәтелгән (11 статьяның 2 һәм 3 өлешләре).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Тәртипнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 5.2.2 пунктында билгеләгәнчә, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелә, моңа Тәртипнең 5.2.3 пунктында аталган социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган әлеге гражданнар категорияләре керми: гадәттән тыш хәлләр, кораллы милләтара (этносара) низаглар аркасында зыян күргән затлар; Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар; хәрби хәрәкәтләр инвалидлары һәм ветераннары; социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар аларның гаиләсендә даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ инвалид (инвалид бала) булуга бәйле рәвештә; шулай ук җан башына уртача keremнәре социаль хезмәтләрне бушлай күрсәтү өчен җан башына уртача керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләменнән түбәнрәк яки аңа тигез булган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар.

Гражданнарга тернәкләндерү хезмәтләрен аларның матди тәэмин ителеше дәрәҗәсенә карап бушлай күрсәтү мәсьәләсе әлеге мөрәҗәгать итүченең шикаяте буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. 2014 елның 29 октябрендәге 60-П номерлы карарындагы хокукый позиция нигезендә республикада билгеләнгән пенсия һәм яшәү минимумы күләме нисбәтеннән чыгып, дәүләт тернәкләндерү хезмәтләрен күрсәтү шартларының дифференциациясе өлкән яшьтәге гражданның һәм инвалидның матди тәэмин ителеше дәрәҗәсе (күләме) кебек объектив хәлне исәпкә алуга нигезләнә. Бу хәл түләүсез тернәкләндерү хезмәтләре рәвешендәге

әһәмиятлерәк социаль ярдәмне әлеге гражданнарның матди ярдәмгә аеруча мохтаҗ категорияләренә күрсәтүне шарт итеп куя. Моннан чыгып, әлеге дифференциация гражданнарны, шул исәптән мөрәҗәгать итүчене дә кимсетә торган һәм аларның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый, чөнки ул гражданнарның социаль яктан аеруча якланмаган категорияләренә ярдәм итүгә юнәлдерелгән, шулай ук федераль законнарның тиешле нормаларына нигезләнә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында берничә мәртәбә гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан теге яисә бу хокукны гамәлгә ашыру шартларында аерымлыклар, әгәр алар объектив акланган, нигезле булса һәм конституциячел әһәмиятле максатларны күздә тотса, ә бу максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар аларга туры килсә, булырга мөмкин дип күрсәтте (2013 елның 30 гыйнварындагы 3-П номерлы, 2013 елның 22 ноябрендәге 25-П номерлы карарлар, 2016 елның 14 гыйнварындагы 135-О номерлы Билгеләмә).

Мондый алым шулай ук 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны гамәлгә ашыруны тикшереп торучы Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану практикасына туры килә, аның нигезендә закон каршында тигез булу хокукы һәм берниди дискриминациясез законны тигез яклау хокукы теләсә кайсы аерымлык дискриминацияле дигәнне аңлатмый, шуңа күрә резонлы һәм объектив критерийларга нигезләнгән дифференциация Пактның 26 статьясы мәгънәсе буенча тыелган дискриминация белән бер үк түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең V бүлегендәге 5.4 бүлекчәсенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, V бүлегендәге 5.2 бүлекчәсенең үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук V бүлегендәге 5.3 бүлекчәсенең 5.3.1 пунктындагы дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләре үзләренең эчтәлеге һәм конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар, шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 13, 28, 52, 54 һәм 58 статьяларына каршы килмиләр.

Гражданин З.М. Вәлиәхмәтовка социаль хезмәтләрне «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәгендә бушлай күрсәтүдән баш тартуга сәбәпче булган хәлләрнең законлы һәм нигезле булу-булмавын тикшерү эшнең факттагы хәлләрен ачыклауны күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы

Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең V бүлегендәге 5.4 бүлекчәсенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, V бүлегендәге 5.2 бүлекчәсенең үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук V бүлегендәге 5.3 бүлекчәсенең 5.3.1 пунктындагы хокукый нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 71-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Р.Я. Гизатуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым подпункта «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан “Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан”»**

19 сентября 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Р.Я. Гизатуллиной,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Р.Я. Гизатуллина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым подпункта «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан “Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан”». Оспариваемой нормой внесено изменение в абзац пятый пункта 1 статьи 5 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», в силу которого ветеранам труда предоставляется субсидия в размере 50 процентов затрат по плате за абонентскую линию сети фиксированной телефонной связи, предоставленной абоненту в постоянное пользование.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является ветераном труда и получает данную субсидию. Она отмечает, что ранее указанная субсидия предоставлялась на затраты по абонентской плате за телефон, однако после принятия оспариваемого законоположения объем социальной поддержки ветеранов труда значительно уменьшился, поскольку субсидия предоставляется только на затраты по плате за абонентскую линию сети фиксированной телефонной связи.

Гражданка Р.Я. Гизатуллина также указывает, что оспариваемый Закон Республики Татарстан был официально опубликован 8 декабря 2015 года и вступил в силу 1 января 2016 года. По ее мнению, отсутствие в обжалуемом нормативном правовом акте положений, определяющих переходный период, при котором гражданам была бы предоставлена возможность адаптироваться к вносимым изменениям, противоречит Конституции Республики Татарстан.

На основании изложенного заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац четвертый

подпункта «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан “Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан”» не соответствующим статьям 13, 28 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Правовые основы деятельности в области связи, полномочия органов государственной власти в области связи, а также права и обязанности лиц, участвующих в указанной деятельности или пользующихся услугами связи, регламентированы Федеральным законом от 7 июля 2003 года № 126-ФЗ «О связи». В соответствии со статьей 47 данного Федерального закона для отдельных категорий пользователей услугами связи законами субъектов Российской Федерации могут устанавливаться льготы и преимущества в части очередности оказания услуг связи, порядка и размера их оплаты (пункт 1); пользователи услугами связи, указанные в пункте 1 данной статьи, обязаны вносить плату за оказанные им услуги связи в полном объеме с последующей компенсацией произведенных ими расходов непосредственно за счет средств бюджета соответствующего уровня (пункт 2).

В Республике Татарстан меры социальной поддержки отдельных категорий населения установлены Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ). Статьей 5 данного Закона Республики Татарстан предусмотрено, что ветеранам труда, пенсия которым назначена в соответствии с федеральными законами «О страховых пенсиях», «О трудовых пенсиях в Российской Федерации» и «О государственном пенсионном обеспечении в Российской Федерации», величина среднемесячного дохода которых на дату обращения не превышает 20 000 рублей, предоставляется в том числе субсидия в размере 50 процентов затрат по плате за абонентскую линию сети фиксированной телефонной связи, предоставленной абоненту в постоянное пользование.

Рассматриваемая субсидия представляет собой дополнительную меру социальной поддержки отдельных категорий граждан, установление которой является правом, а не обязанностью Республики Татарстан. Условия предоставления и размер данной выплаты определяются республиканским законодателем с учетом реальных возможностей бюджета Республики Татарстан по обеспечению этих выплат, что непосредственно вытекает из содержания пункта 1 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», согласно которому расходы на реализацию мер социальной поддержки населения, установленных данным Законом, производятся за счет средств бюджета Республики Татарстан и местных бюджетов в объемах переданных финансовых средств.

Конституционный Суд Российской Федерации неоднократно

отмечал, что, относя социальную защиту, включая социальное обеспечение, к совместному ведению Российской Федерации и ее субъектов (статья 72, пункт «ж» части 1), Конституция Российской Федерации не устанавливает конкретные способы и объемы такой защиты, предоставляемой тем или иным категориям граждан. Решение этих вопросов является прерогативой законодателя, который при определении гарантий реализации прав, закрепленных в Конституции Российской Федерации, располагает достаточно широкой свободой усмотрения в выборе мер социальной защиты, критериев их дифференциации, регламентации условий и порядка предоставления; он вправе также избирать и изменять формы (способы) их предоставления (Постановление от 10 ноября 2009 года № 17-П; Определение от 9 ноября 2010 года № 1439-О-О).

Учитывая изложенное, оспариваемое правовое регулирование принято Государственным Советом Республики Татарстан в пределах своих дискреционных полномочий, обусловлено необходимостью обеспечения государством конституционной обязанности по реализации гарантий социальной защиты определенных категорий граждан с учетом имеющихся у республики на данном этапе социально-экономического развития финансовых и иных средств и возможностей, само по себе не может рассматриваться как нарушающее конституционные права граждан и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой. Разрешение же поставленного ею вопроса об изменении размера предоставляемой ветеранам труда субсидии предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию республиканского законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Относительно доводов гражданки Р.Я. Гизатуллиной о порядке вступления в силу рассматриваемого Закона Республики Татарстан следует отметить, что в соответствии со статьей 5 Закона Республики Татарстан от 31 октября 2002 года № 21-ЗРТ «О порядке опубликования и вступления в силу законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина» днем официального опубликования нормативных правовых актов Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина считается в том числе первое размещение (опубликование) их полного текста на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU). Согласно статье 6 приведенного Закона Республики Татарстан нормативные правовые акты Республики Татарстан по вопросам защиты прав и свобод человека и гражданина вступают в силу через 10 дней после их офици-

ального опубликования, если самими актами не установлен иной, более поздний, срок вступления их в силу.

Оспариваемый заявительницей нормативный правовой акт был официально опубликован 8 декабря 2015 года на указанном официальном портале, при этом им установлен более поздний срок вступления его в силу, а именно 1 января 2016 года, что соответствует требованиям действующего законодательства, не нарушает, не ограничивает и не умаляет конституционные права человека и гражданина и, следовательно, в этой части также не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Р.Я. Гизатуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым подпункта «а» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан “Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан”», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Р.Я. Гизатуллиной и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 15-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.Я. Гыйззәтуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
19 сентябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Я. Гыйззәтуллина шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Я. Гыйззәтуллина «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъвалана торган норма белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 пунктының бишенче абзацына үзгәреш кертелгән, аның нигезендә хезмәт ветераннарына чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия бирелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — хезмәт ветераны һәм әлеге субсидияне алучы. Ул билгеләгәнчә, элегрәк әлеге субсидия телефон өчен абонент түләве чыгымнарына бирелгән, ләкин дәгъвалана торган закон нигезләмәсе кабул ителгәч, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күләме шактый кимегән, чөнки субсидия чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе өчен түләү чыгымнарына гына бирелә.

Гражданка Р.Я. Гыйззәтуллина шулай ук күрсәткәнчә, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законы 2015 елның 8 декабрендә рәсми басылып чыккан һәм 2016 елның 1 гыйнварында үз көченә кергән. Аның фикеренчә, дәгъвалана торган норматив хокукый актта гражданнарга кертелә торган үзгәрешләргә ияләшү мөмкинлеген бирә торган күчеш чорын билгеләгән нигезләмәләрнең булмавы Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлекнең хокукый нигезләре, дәүләт хакимияте органнарының элемтә өлкәсендәге вәкаләтләре, шулай ук күрсәтелгән эшчәнлектә катнашучы яки элемтә хезмәтләреннән файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары «Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль закон белән регламентлаштырылган. Әлеге Федераль законның 47 статьясы нигезендә элемтә хезмәтләрен кулланучыларның аерым категорияләре өчен Россия Федерациясе субъектларының законнары белән элемтә хезмәтләрен күрсәтү чираты, алар өчен түләү тәртибе һәм күләме өлешендә ташламалар билгеләнергә мөмкин (1 пункт); әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән элемтә хезмәтләрен кулланучылар аларга күрсәтелгән элемтә хезмәтләре өчен түләүне тулы күләмдә кертергә тиеш, аннан соң аларның чыгымнары тиешле дәрәҗәдәге бюджет акчалары хисабына компенсацияләнәчәк (2 пункт).

Татарстан Республикасында халыкның социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган аерым категорияләре «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) билгеләнгән. Әлеге Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында каралганча, «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән, мөрәҗәгать иткән көнгә уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына шул исәптән чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия бирелә.

Карала торган субсидия гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора. Әлеге түләүне бирү шартлары һәм күләме, бу түләүләрне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы бюджетының реаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, республика закон чыгаручысы тарафыннан билгеләнә, бу исә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты эчтәлегеннән килеп чыга, аның буенча халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең әлеге Законда

билгеләнгән чараларын гамәлгә ашыру чыгымнары тапшырылган финанс чаралары күләмнәрендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентацияләүне сайлап алганда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, дәгъвалана торган хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында кабул ителгән, гражданнарның билгеле категорияләрен социаль яклау гарантияләрен гамәлгә ашыру буенча дәүләтнең конституциячел бурычын әлеге социаль-икътисади үсеш этабында республиканың финанс һәм башка чараларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып тәэмин итү кирәклегенә бәйле, үзеннән-үзе гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган итеп карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый. Хезмәт ветераннарына бирелә торган субсидия күләмен үзгәртү турындагы ул куйган мәсьәләне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Гражданка Р.Я. Гыйззәтуллинаның карала торган Татарстан Республикасы Законының үз көченә керү тәртибе турындагы дәлилләренә карата шуны билгеләп үтәргә кирәк: «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре

буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару көне булып шул исәптән аларның тулы текстын «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Китерелгән Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы буенча кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары рәсми басылып чыккан көннәреннән соң 10 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр актларның үзләрендә аларның бүтән, соңрак, үз көченә керү вакыты билгеләнгән булмаса.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый акт күрсәтелгән рәсми порталда 2015 елның 8 декабрендә рәсми басылып чыккан, шул ук вакытта анда аның соңрак үз көченә керү вакыты итеп, атап әйткәндә, 2016 елның 1 гыйнвары билгеләнгән, бу исә гамәлдәге законнарның таләпләренә туры килә, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын бозмый, чикләми һәм киметми һәм, димәк, бу өлештә дә аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.Я. Гыйззәтуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә ул карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.Я. Гыйззәтуллинага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 15-О

Татарстан Республикасы Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Э.Г. Гатауллина на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 1.3 Положения о целевой субсидии на сглаживание роста платы граждан за жилищно-коммунальные услуги, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 27 августа 2012 года № 738 «О предоставлении целевой субсидии на сглаживание роста платы граждан за жилищно-коммунальные услуги гражданам, проживающим в жилых помещениях, теплоснабжение которых осуществляется ОАО "Таттеплосбыт", поставляющим тепловую энергию, производимую в режиме комбинированной выработки на территории Республики Татарстан, и гражданам п.г.т. Уруссу Ютазинского муниципального района, проживающим в жилых помещениях, теплоснабжение которых осуществляется ЗАО "ТГК Уруссинская ГРЭС"»**

19 сентября 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина Э.Г. Гатауллина,

**у с т а н о в и л :**

Таким образом, обжалуемая часть 4 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции Республики Татарстан и не

может рассматриваться как нарушающая конституционные права и свободы человека и гражданина, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Г.Н. Юсиповой не является допустимой. Внесение же целесообразных, с точки зрения заявительницы, изменений в оспариваемый Закон Республики Татарстан, касающихся срока, по истечении которого у собственников жилых помещений возникает обязанность по уплате взносов на капитальный ремонт, не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 4 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.Н. Юсиповой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 18-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
21 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәдә урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча расланган региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап ике календарь ай үткәннән соң барлыкка килә дип билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова — 1960 елда Казан шәһәрендә төзелгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе. Ул күрсәткәнчә, дәгъвалана торган норма нигезендә аның капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге күпфатирлы йорт кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча расланган региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап, Россия Федерациясе Торак кодексының 169 статьясындагы 3 өлешендә каралганча, сигез календарь ай үткәннән соң түгел, ә ике календарь ай үткәннән соң барлыкка килә.

Мөрәҗәгать итүче, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысының күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычының иртәрәк барлыкка килү вакытын билгеләү хокукы күрсәтелгән бурычның артык иртә барлыкка килү вакытын кую мөмкинлеген күздә

тотмый, дип саный. Аның фикеренчә, карала торган Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән ике календарь айга тигез булган вакыт гражданнарга өстәмә финанс чыгымнар йөкли торган яңа шартларга ияләшергә мөмкинлек бирми, бу исә гражданнарның конституциячел хокукларын боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче өлеш), 49 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «к» пункты) нигезендә торак законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының әлеге өлкәдәге законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 169 статьясындагы 3 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге күпфатирлы йорт кертелгән капиталь ремонт буенча расланган региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап, Россия Федерациясе субъекты законы белән иртәрәк вакыт билгеләнгән булмаса, сигез календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Шулай итеп, әлеге норма Россия Федерациясе субъектларына күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы иртәрәк барлыкка килә торган вакытны билгеләү хокукын бирә. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү максатында «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында ике календарь айга тигез булган вакыт каралган.

Шул рәвешле, дәгъвалана торган норма белән билгеләнгән җайга салу үзенең хокукый асылы буенча республика закон чыгаручысы тарафыннан үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, мондый җайга салуны гамәлгә ашырганда федераль закон чыгаручы тарафыннан шактый киң ирек бирелүгә бәйле һәм йорттагы урыннар милекчеләренә федераль законда каралмаган нинди дә булса өстәмә бурычның йөкләнүен күрсәтми.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы дәгъвалана торган 4 өлешендә аның Татарстан Республикасы Конституциясенә

туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм ул кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Г.Н. Юсипованың шикаяте карала алмый. Ә дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законына торак урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы барлыкка килә торган вакытка карата мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 18-О

Татарстан Республикасы Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем седьмым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год»**

8 ноября
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.Н. Юсипова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем седьмым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год».

Оспариваемая норма устанавливает на период с 1 июля 2016 года по 31 декабря 2016 года для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, плату за содержание контейнерных площадок в размере 0,29 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является собственником жилого помещения в многоквартирном доме в городе Казани и оплачивает услугу по содержанию контейнерных площадок в соответствии с обжалуемым положением. Между тем она отмечает, что установление в оспариваемом положении тарифа за содержание контейнерных площадок влечет за собой взимание двойной платы. В обоснование своей позиции заявительница ссылается на противоречие рассматриваемой нормы подпунктам 2.5 и 3.2 Минимального перечня работ и услуг по содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 апреля 2010 года № 251 «О мерах по развитию конкуренции в сфере управления многоквартирными до-

мами», согласно которым уборка контейнерных площадок входит в перечень работ по содержанию придомовой территории, а также разделу 3 Методических рекомендаций по расчету размера платы за жилищные услуги, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 апреля 2010 года № 250 «О мерах по повышению качества оказываемых населению жилищных и коммунальных услуг и обоснованности размера платы за них», предусматривающему, что затраты по содержанию контейнерных площадок включаются в структуру тарифа на услугу «Вывоз ТБО».

На основании изложенного гражданка Г.Н. Юсипова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац седьмой пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49, 51 и 55 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с пунктом 1 части 2 статьи 154 во взаимосвязи с частью 1 статьи 156 Жилищного кодекса Российской Федерации плата за жилое помещение и коммунальные услуги для собственника помещения в многоквартирном доме включает в себя плату за содержание и текущий ремонт общего имущества в многоквартирном доме, установленную в размере, обеспечивающем содержание общего имущества в многоквартирном доме в соответствии с требованиями законодательства. Отношения по содержанию общего имущества, принадлежащего на праве общей долевой собственности собственникам помещений в многоквартирном доме, согласно части 3 статьи 39 указанного Кодекса, регулируются Правилами содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденными постановлением Правительства Российской Федерации от 13 августа 2006 года № 491 (далее — Правила). В соответствии с подпунктами «е» и «ж» пункта 2 Правил в состав общего имущества включаются земельный участок, на котором расположен многоквартирный дом, с элементами озеленения и благоустройства и иные объекты, расположенные в границах указанного земельного участка и предназначенные для обслуживания, эксплуатации и благоустройства многоквартирного дома. Содержание общего имущества, согласно указанным Правилам, включает в себя в том числе уборку и санитарно-гигиеническую очистку помещений общего пользования, а также земельного участка, входящего в состав общего имущества; сбор и вывоз твердых и жидких бытовых отходов; содержание, текущий и капитальный ремонт предназначенных для обслуживания, эксплуатации и благоустройства этого многоквартирного дома объектов, расположенных на земельном участке, входящем в состав общего имущества (подпункты «г», «д», «з» пункта 11).

Уборка контейнерных площадок, расположенных на придомовой территории общего имущества многоквартирного дома,

относится к работам и услугам по содержанию общего имущества в многоквартирном доме, как это установлено абзацем шестым пункта 24 и абзацем третьим пункта 25 раздела III Минимального перечня услуг и работ, необходимых для обеспечения надлежащего содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденного постановлением Правительства Российской Федерации от 3 апреля 2013 года № 290.

Согласно частям 1 и 2 статьи 39 во взаимосвязи с частью 1 статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации собственники помещений в многоквартирном доме обязаны нести бремя расходов на содержание общего имущества соразмерно своим долям в праве общей собственности на это имущество путем внесения платы за содержание и ремонт жилого помещения в многоквартирном доме. В соответствии с частью 1 статьи 37 данного Кодекса доля в праве общей собственности на общее имущество в многоквартирном доме собственника помещения в этом доме пропорциональна размеру общей площади указанного помещения.

При этом, исходя из смысла частей 7 и 8 статьи 156 Жилищного кодекса Российской Федерации, размер платы за содержание жилого помещения в многоквартирном доме, в котором не созданы товарищество собственников жилья либо жилищный кооператив или иной специализированный потребительский кооператив, а также размер обязательных платежей, связанных с оплатой расходов на содержание и ремонт общего имущества в многоквартирном доме, определяются на общем собрании собственников помещений в таком доме или органами управления товарищества собственников жилья либо органами управления жилищного кооператива или органами управления иного специализированного потребительского кооператива. Закрепляя на законодательном уровне приоритет на право регулирования ценообразования в жилищной сфере за собственниками помещений в многоквартирном доме, Жилищный кодекс Российской Федерации в силу части 3 статьи 156 и части 4 статьи 158 предусматривает, что, если собственники жилых помещений не приняли решение о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на их общем собрании не приняли решение об установлении размера платы за содержание жилого помещения, такой размер устанавливается органом местного самоуправления.

По своей правовой природе обжалуемый муниципальный нормативный правовой акт распространяется на собственников помещений в многоквартирных домах, которые не воспользовались своим правом на самостоятельное принятие решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) об установлении размера платы за содержание жилых помещений по видам услуг. Оспариваемое правовое регулирование принято Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани в пределах предоставленных ему полномочий, основано на указанных выше положениях федерального законодательства и не содержит ограничений в реализации собственниками помещений в многоквартирных домах права по принятию на общем собрании

собственников решения, в том числе об определении размера платы за содержание контейнерных площадок, условиях и порядке ее внесения. Следовательно, обжалуемое нормативное положение не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой.

Относительно доводов заявительницы о противоречии обжалуемой нормы отдельным положениям Минимального перечня работ и услуг по содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 апреля 2010 года № 251 «О мерах по развитию конкуренции в сфере управления многоквартирными домами», и Методических рекомендаций по расчету размера платы за жилищные услуги, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 апреля 2010 года № 250 «О мерах по повышению качества оказываемых населению жилищных и коммунальных услуг и обоснованности размера платы за них», следует отметить, что жалоба в этой части также не может быть принята Конституционным судом Республики Татарстан к рассмотрению, поскольку разрешение вопроса о соответствии муниципального нормативного правового акта подзаконному нормативному правовому акту не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем седьмым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан

по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.Н. Юсиповой, в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани и Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 19-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торган өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы җиденче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
8 ноябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торган өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы җиденче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган норма социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәрге чор өчен контейнер мәйданнарын карап тотуга түләүне айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 0,29 сум күләмендә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — Казан шәһәрендәге күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе һәм ул контейнер мәйданнарын карап тоту хезмәте өчен дәгъвалана торган нигезләмә буенча түләп бара. Шул ук вакытта ул күрсәткәнчә, дәгъвалана торган нигезләмәдә контейнер мәйданнарын карап тоту өчен тариф билгеләү икеләтә түләү алынуга китерә. Үз позициясен нигезләп, мөрәҗәгать итүче карала торган норманың әлеге нигезләмәләргә каршы килүен күрсәтә: «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

2010 елның 9 апрелендәге 251 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрнең һәм хезмәтләрнең минималь исемлегенең 2.5 һәм 3.2 пунктчалары, алар нигезендә контейнер мәйданнарын җыештыру йорт яны территориясен карап тоту буенча эшләр исемлегенә керә, шулай ук «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын һәм алар өчен түләү күләменең нигезле булуын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 9 апрелендәге 250 номерлы карары белән расланган Торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплап чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең контейнер мәйданнарын карап тотуга чыгымнарның «Каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару» хезмәте тарифы структурасына кертелүен күздә тота торган 3 бүлеге.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы җиденче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49, 51 һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 154 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 156 статьясындагы 1 өлеше нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә күпфатирлы йорттагы урын милекчесе өчен күпфатирлы йорттагы уртак милекне законнар таләпләре нигезендә карап тотуны тәэмин итәрлек күләмдә билгеләнгән күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту һәм аңа агымдагы ремонт ясауга түләү керә. Күрсәтелгән Кодексның 39 статьясындагы 3 өлеше буенча күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак өлешле милек хокукында булган уртак милекләрен карап тоту буенча мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту кагыйдәләре (алга таба — Кагыйдәләр) белән җайга салына. Кагыйдәләрнең 2 пунктындагы «е» һәм «ж» пунктчалары нигезендә уртак милек составына яшелләндерү һәм төзекләндерү элементлары белән күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеге һәм күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан һәм күпфатирлы йортка хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен каралган башка объектлар керә. Күрсәтелгән Кагыйдәләр буенча уртак милекне карап тотуга шул исәптән гомуми кулланылыштагы урыннарны, шулай ук уртак милек составына керә торган җир кишәрлеген җыештыру һәм санитар-гигиеник чистарту; каты һәм сыек көнкүреш калдыкларын читкә чыгару; уртак милек составына кергән җир кишәрлегендә урнашкан әлеге күпфатирлы йортка хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен ка-

ралган объектларны карап тоту, аларга агымдагы һәм капиталь ремонт ясау керә (11 пунктның «г», «д», «з» пунктчалары).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләрнең минималь исемлегенең III бүлегендәге 24 пунктының алтынчы абзацы һәм 25 пунктының өченче абзацы белән билгеләнгәнчә, күпфатирлы йортның уртак милегенең йорт яны территориясендә урнашкан контейнер мәйданнарын җыештыру күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту буенча эшләр һәм хезмәтләргә карый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре белән үзара бәйләнештә 158 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре уртак милекне карап тотуга чыгымнарны, әлеге мөлкәткә уртак милек хокукындагы өлешләренә карап, күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүне кертү юлы белән үз өсләренә алырга тиеш. Әлеге Кодекснең 37 статьясындагы 1 өлеше буенча күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә уртак милек хокукында шул йорттагы урын милекчесенең өлеше күрсәтелгән урынның гомуми мәйданы күләменә пропорциональ була.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре мәгънәсеннән чыгып, торак милекчеләре ширкәте яисә торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы төзелмәгән күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту һәм ремонтлауга чыгымнарны каплау белән бәйле мәҗбүри түләүләр күләме андый йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында яки торак милекчеләре ширкәтенең идарә органнары яисә торак кооперативының идарә органнары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативының идарә органнары тарафыннан билгеләнә. Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең торак өлкәсендә бәяләр билгеләүне җайга салуга хокукларының өстенлеген законнар дәрәҗәсендә беркетеп, Россия Федерациясе Торак кодексы 156 статьясының 3 өлеше һәм 158 статьясының 4 өлеше нигезендә шуны күздә тота: әгәр торак урыннар милекчеләре күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән һәм (яки) үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

Үзенең хокукый табигате буенча дәгъвалана торган муниципаль норматив хокукый акт күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу һәм (яки) торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен хезмәт күрсәтү төрләре буенча билгеләү турында мөстәкыйль карар кабул итү хокукларыннан файдаланмаган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кагыла. Дәгъвалана торган хокукый җайга салу Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан үзенә бирелгән

вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән, югарыда китерелгән федераль законнар нигезләмәләренә таянган һәм күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең үзләренең гомуми җыелышында шул исәптән контейнер мәйданнарын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, аны кертү шартлары һәм тәртибе турында карар кабул итү хокукын гамәлгә ашыруларында чикләүләр куймый. Димәк, дәгъвалана торган норматив нигезләмәдә аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Дәгъвалана торган норманың «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 9 апрелендәге 251 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрнең һәм хезмәтләрнең минималь исемлегенең һәм «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын һәм алар өчен түләү күләменең нигезле булуын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 9 апрелендәге 250 номерлы карары белән расланган Торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплап чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең аерым нигезләмәләренә каршы килүе турындагы мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә карата шуны билгеләп үтәргә кирәк: шикаять әлеге өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга шулай ук алына алмый, чөнки муниципаль норматив хокукый актның законга буйсынулы норматив хокукый актка туры килү-килмәве турындагы мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы җиденче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре

бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 19-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.С. Насыровой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год»**

14 ноября
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки А.С. Насыровой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка А.С. Насырова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год».

Оспариваемое заявительницей нормативное положение устанавливает на период с 1 июля 2016 года по 31 декабря 2016 года для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, плату за вывоз твердых бытовых отходов в размере 2,80 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является собственником жилого помещения в многоквартирном доме. В настоящее время у нее имеется задолженность перед обществом с ограниченной ответственностью «Управляющая компания “Уютный дом”» (далее — Управляющая компания) по оплате услуги «Вывоз твердых бытовых отходов». Заявительница отмечает, что образование данной задолженности было вызвано ее несогласием с тарифами за эту услугу. По ее мнению, установление общей площади жилого помещения в качестве единицы измерения, в соответствии с которой взимается указанная плата, является неправомерным, поскольку количество бытовых отходов может зависеть только от количества проживающих в жилом помещении граждан, а не от его общей площади.

Ново-Савиновский районный суд города Казани по иску

Управляющей компании своим решением постановил взыскать с гражданки А.С. Насыровой задолженность по указанной услуге. В удовлетворении встречных исковых требований гражданки А.С. Насыровой к Управляющей компании о признании начислений по услуге «Вывоз твердых бытовых отходов» неправомерными судом было отказано. Апелляционным определением судебной коллегии по гражданским делам Верховного суда Республики Татарстан указанное судебное решение было изменено в части, касающейся суммы, подлежащей взысканию с заявительницы.

Гражданка А.С. Насырова также указывает на противоречие оспариваемой нормы пункту 1 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 19 февраля 2010 года № 85 «О мерах по повышению эффективности системы защиты прав и интересов населения при предоставлении жилищных и коммунальных услуг», согласно которому в целях повышения эффективности системы защиты прав и интересов населения при предоставлении услуг организациями коммунального комплекса было принято предложение органов местного самоуправления в Республике Татарстан о необходимости реформирования с 1 марта 2010 года системы оплаты жилищно-коммунальных услуг в том числе путем установления платы за вывоз и утилизацию отходов с человека.

На основании изложенного заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац шестой пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49, 55 и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Конституционный суд Республики Татарстан, изучив представленные гражданкой А.С. Насыровой материалы, не находит оснований для принятия ее жалобы к рассмотрению.

Вопрос правомерности установления в оспариваемой норме квадратного метра в качестве единицы измерения, в соответствии с которой взимается плата за вывоз твердых бытовых отходов, уже был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. В своем определении от 21 октября 2016 года № 17-О Конституционный суд Республики Татарстан указал, что собственники помещений, исходя из взаимосвязанных положений частей 1 и 2 статьи 39 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также пункта 28 Правил содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 13 августа 2006 года № 491, обязаны нести бремя расходов на содержание общего имущества соразмерно своим долям в праве общей собственности на это имущество путем внесения платы за содержание и ремонт жилого помещения в многоквартирном доме. Определение долей собственников в праве общей собственности на общее имущество в многоквартирном доме связано с размером площади жилого помещения, принадлежащего собственнику. Единицей измерения данной величины является

квадратный метр общей площади жилого помещения. Исходя из этого, Конституционный суд Республики Татарстан пришел к выводу, что обжалуемое нормативное положение не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, поскольку оно основано на положениях федерального законодательства, принято в пределах предоставленных Исполнительному комитету муниципального образования города Казани полномочий, и не содержит ограничений в реализации собственниками помещений в многоквартирных домах права по принятию на общем собрании собственников решения, в том числе об определении размера платы за вывоз твердых бытовых отходов, условиях и порядке ее внесения.

Относительно вопроса о соответствии оспариваемого муниципального нормативного правового акта постановлению Кабинета Министров Республики Татарстан «О мерах по повышению эффективности системы защиты прав и интересов населения при предоставлении жилищных и коммунальных услуг» Конституционный суд Республики Татарстан в вышеназванном определении указал, что его разрешение в соответствии со статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.С. Насыровой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем шестым пункта 3 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке А.С. Насыровой, в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани и Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 20-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Ә.С. Насыйрова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
14 ноябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Ә.С. Насыйрова шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Ә.С. Насыйрова «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмә социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәрге чор өчен каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару буенча түләүне айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 2,80 сум күләмендә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе. Хәзерге вакытта аның «“Уютный дом” идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (алга таба — Идарәче компания) «Каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару» хезмәте өчен түләү буенча бурычы бар. Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, әлеге бурычның барлыкка килүе аның бу хезмәт өчен куелган тарифлар белән килешмәвенә бәйле. Аның фикеренчә, торак урынның гомуми мәйданын әлеге түләү алына торган үлчәү берәмлеге буларак

билгеләү хокуксыз, чөнки көнкүреш калдыклары күләме торак урынның гомуми мәйданына түгел, ә анда яшәүче гражданнар санына гына бәйле булырга мөмкин.

Казан шәһәре Яңа Савин район суды Идарәче компания дәгъвасы буенча гражданка Ә.С. Насыйровадан әлеге хезмәт буенча бурычын түләттерергә карар кылган. Гражданка Ә.С. Насыйрованың «Каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару» хезмәте буенча исәпләнгән суммаларны хокуксыз дип тану турындагы Идарәче компаниягә каршы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән суд баш тарткан. Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән күрсәтелгән суд карары мөрәҗәгать итүчедән түләттерелергә тиешле суммага кагылган өлешендә үзгәртелгән.

Гражданка Ә.С. Насыйрова шулай ук дәгъвалана торган норманың «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 пунктына каршы килүен күрсәтә, аның нигезендә коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарының 2010 елның 1 мартыннан торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү системасын шул исәптән калдыкларны чыгарган һәм утильләштергән өчен түләүне кеше башыннан чыгып кертү юлы белән реформалаштыру зарурлыгы турындагы тәкъдиме кабул ителгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы алтынчы абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49, 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка Ә.С. Насыйрова тапшырган материалларны өйрәнеп, аның шикаятен карауга алу өчен нигезләр тапмый.

Дәгъвалана торган нормада квадрат метрны каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару өчен түләү алына торган үлчәү берәмлеге буларак билгеләүнең законлы булу-булмавы турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең 2016 елның 21 октябрендәге 17-О номерлы билгеләмәсендә урыннар милекчеләре, Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләренең үзара бәйләнештәге нигезләмәләреннән, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары

белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту кагыйдәләренең 28 пунктыннан чыгып, уртак милекне карап тотуга чыгымнарны, әлеге милеккә уртак милек хокукындагы өлешләренә карап, күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүне кертү юлы белән үз өсләренә алырга тиеш дип күрсәтте. Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә уртак милек хокукында милекчеләрнең өлешләрен билгеләү милекченең торак урыны мәйданы күләменә бәйле. Әлеге күләмнең үлчәү берәмлеге булып торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры тора. Моннан чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъвалана торган норматив нигезләмәдә ул федераль законнар нигезләмәләренә таянганга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына бирелгән вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгәнгә күрә, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең үзләренең гомуми җыелышында шул исәптән каты көнкүреш калдыкларын читкә чыгару өчен түләү күләмен билгеләү, аны кертү шартлары һәм тәртибе турында карар кабул итү хокукын гамәлгә ашыруларында чикләүләр куелмаган дигән нәтиҗәгә килде.

Дәгъвалана торган муниципаль норматив хокукый актның «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына каршы килүе турындагы мәсьәләгә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды югарыда аталган билгеләмәсендә аны хәл итү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судының компетенциясенә керми дип күрсәтте.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем вторым пункта 1 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 29 июня 2013 года № 450 «Об установлении минимального размера взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.Н. Юсиповой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 25-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
28 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгәннән соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмә Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен мондый урын милекчесенә карый торган күпфатирлы йорттагы урынның бер квадрат метр гомуми мәйданына бер айга 5 сум күләмендә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова — 1960 елда төзелгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе. 2014 елда әлеге йортка капиталь ремонт ясалган.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, дәгъва белдерелә торган норма, йортның төзелү елын, ничә катлы булуын, күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлекне, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр исемлеген исәпкә алмыйча, бөтен күпфатирлы йортларга карата капиталь ремонт өчен кертемнең бертөрле минималь күләмен билгели, бу исә аның конституциячел хокукларын бозуга китерә.

Гражданка Г.Н. Юсипова ассызыклаганча, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъектларына капиталь ремонт өчен кертемнең дифференциацияләнгән минималь күләмен билгеләү хокукын биргән. Республика закон чыгаручысы үз чиратында күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь

ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырган. Ләкин Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүче уйлавынча, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең дифференциацияләнгән минималь күләмен билгеләү турындагы федераль һәм республика законнары таләпләрен исәпкә алмаган һәм андый кертемнең бердәм минималь күләмен билгеләгән.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 7 февралендәге 41/пр номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты тарафыннан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрнең 8.1 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектына кертемнең минималь күләмен билгеләгәндә һәм кертемнең билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фондларындагы акчалар хисабына күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны финанслаганда кулланыла торган шушы ук пунктта саналган мәгълүматларны бастырып чыгарырга тәкъдим ителә. Шул ук вакытта күрсәтелгән Методик тәкъдимнәрнең 8.2 пункты нигезендә әлеге мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектының капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгели торган норматив хокукый актына кушымтага (кушымталарга) кертергә тәкъдим ителә. Ләкин, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, дәгъва белдерелә торган нигезләмә белән капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме күрсәтелгән мәгълүматларны бастырып чыгармыйча билгеләнгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче өлеш), 49 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 8.1 пункты буенча капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорттагы урын милекчесе биләгән урынның гомуми мәйданыннан чыгып билгеләнә һәм күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлеккә карап, йортның төрен һәм ничә катлы булуын, күпфатирлы йорттагы төзелеш конструкцияләренең аерым элементларына һәм инженерлык системаларына капиталь ремонт ясау хакын, чираттагы капиталь ремонт ясаганчы алардан нәтиҗәле файдалануның норматив срокларын (ремонтара норма-

тив сроклар) исәпкә алып, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча әлеге Кодекста һәм Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актында билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып дифференциацияләнергә мөмкин.

Дәгъва белдерелә торган карарны кабул итү моментына Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге 288 номерлы боерыгы белән расланган Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр гамәлдә булган, алар хәзер үз көчен югалткан. Әлеге Методик тәкъдимнәрнең 1.3 пункты мәгънәсе буенча Россия Федерациясе субъектына күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләүне күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне финанслау өчен акчаларга гомуми ихтыяҗны билгеләү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә гомуми чыгымнарны исәпкә алып, гражданнарга — күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кертемнең минималь күләме түләрлек булу, кертемнең билгеләнә торган минималь күләменнән чыгып булдырыла торган финанс чараларының җитәрлеге принциплары нигезендә башкарырга тәкъдим ителгән.

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләүнең тиңдәш принциплары хәзерге вакытта «Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 июнендәге 454/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

Федераль законнарның китерелгән нигезләмәләрен, шулай ук «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карар кабул ителгән. Дәгъвалана торган нормада каралган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме беренче чиратта капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм эшләрнең билгеле исемлеген финанслау тиешлегенә, гражданнарга — күпфатирлы йортлардагы фатирлар милекчеләренә түләрлек булуына бәйле һәм үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонтны вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлгән.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны

оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 июлендәге 519 номерлы карары белән законнарда билгеләнгән тәртиптә басылып чыккан Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге расланган.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган җайга салуда аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Татарстан Республикасындагы күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен үзгәртү турында ул куйган сорауны хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды гамәлдәге җайга салуда милекчеләрнең күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау белән бәйле чыгымнарны финанслау күләмен үзгәртү хокукларын гамәлгә ашыруларында чикләүләр булмавына игътибар итә, бу Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 8.2 өлешендә каралган, аның нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемне Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнгән шундый кертемнең минималь күләменнән күбрәк күләмдә билгеләү турында карар кабул итә алалар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республи-

касы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 25-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Р.З. Камалова на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 4 пункта 1 статьи 6 Закона Республики Татарстан от 29 ноября 2002 года № 24-ЗРТ «О транспортном налоге» (в редакции Закона Республики Татарстан от 28 ноября 2005 года № 115-ЗРТ)**

28 декабря
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

предварительно изучив на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалобу гражданина Р.З. Камалова,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступили жалоба гражданина Р.З. Камалова и дополнение к ней на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 4 пункта 1 статьи 6 Закона Республики Татарстан от 29 ноября 2002 года № 24-ЗРТ «О транспортном налоге».

Оспариваемое заявителем нормативное положение устанавливает, что транспортные средства, зарегистрированные на инвалидов I и II групп, имеющих в собственности автомобили с мощностью двигателя до 100 лошадиных сил (до 73,55 кВт), освобождаются от налогообложения.

Как следует из жалобы, дополнения к ней и приложенных копий документов, заявитель является инвалидом II группы и имеет в собственности автомобиль с мощностью двигателя 104,72 лошадиных сил. Он обращался в Межрайонную инспекцию Федеральной налоговой службы № 4 по Республике Татарстан по вопросу льготного налогообложения его автомобиля. Однако, как следует из письма указанного налогового органа, данная льгота ему не может быть предоставлена, поскольку согласно пункту 1 статьи 6 Закона Республики Татарстан от 29 ноября 2002 года № 24-ЗРТ «О транспортном налоге» (в редакции Закона Республики Татарстан от 28 ноября 2005 года № 115-ЗРТ) от уплаты транспортного налога освобождаются инвалиды I и II групп, имеющие в собственности автомобили с мощностью двигателя до 100 лошадиных сил. В связи с этим гражданин Р.З. Камалов обратился с иском об отмене отдельных норм оспариваемого Закона Республики Татарстан и компенсации морального вреда в Приволжский районный суд города Казани, который своим определением возвратил ему данное исковое заявление.

Заявитель отмечает, что законодателем Республики Татарстан не было учтено техническое усовершенствование современных автомобилей в части их мощности и повышения безопасности при управлении. Оспариваемое положение, по его мнению, ограничивает автолюбителей, имеющих льготы по инвалидности, в их праве приобретать современные автомобили с повышенными возмож-

ностями безопасной езды. Он считает, что инвалиды I и II групп, имеющие в собственности автомобили с мощностью двигателя свыше 100 лошадиных сил, должны оплачивать транспортный налог только в пределах превышения установленной мощности, что соответствовало бы закрепленным в Конституции Республики Татарстан принципам правового и социального государства.

На основании изложенного гражданин Р.З. Камалов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать подпункт 4 пункта 1 статьи 6 Закона Республики Татарстан от 29 ноября 2002 года № 24-ЗРТ «О транспортном налоге» не соответствующим статьям 3, 7, 13, 28 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Вопросы, касающиеся условий и порядка предоставления мер социальной поддержки, включая льготы по уплате транспортного налога, уже были предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан, который в своем постановлении от 3 июля 2014 года № 59-П указал, что Конституция Республики Татарстан, так же как и Конституция Российской Федерации, не устанавливает конкретные виды и объемы социальной защиты, предоставляемой различным категориям граждан, исходя из чего республиканский законодатель обладает определенной свободой усмотрения при регулировании отношений, связанных с предоставлением мер социальной поддержки, включая льготы по уплате региональных налогов, к которым относится транспортный налог. Устанавливая для инвалидов I и II групп льготу по уплате транспортного налога, законодатель Республики Татарстан был вправе дифференцировать основания ее предоставления исходя из конкретного вида транспортного средства — автомобиля с мощностью двигателя до 100 лошадиных сил (до 73,55 кВт), собственником которого является инвалид. При этом вид транспортного средства, а также объем предоставляемой налоговой льготы определены в оспариваемой норме с учетом объективно значимых критериев, характеризующих как указанную категорию граждан, нуждающихся в силу состояния своего здоровья в дополнительной по сравнению с другими гражданами социальной поддержке, так и финансовых возможностей республики. Данное регулирование согласуется с конституционными принципами равенства и соразмерности (статьи 28 (части первая и вторая) и 58 Конституции Республики Татарстан) в сфере налоговых отношений, поскольку предусмотренная в оспариваемой норме налоговая льгота распространяется на всех без исключения инвалидов I и II групп, имеющих в собственности автомобили с мощностью двигателя до 100 лошадиных сил (до 73,55 кВт), а также не преследует цели отрицания или умаления прав и свобод человека и гражданина.

Приведенная правовая позиция Конституционного суда Республики Татарстан сохраняет свою силу.

Таким образом, поскольку предметом обращения гражданина Р.З. Камалова является положение, относительно которого Конституционным судом Республики Татарстан уже вынесено постановление, сохраняющее свою силу, жалоба заявителя на основании

пункта 3 части первой статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не может быть принята к рассмотрению. Разрешение же поставленного им вопроса об изменении тарифов транспортного налога предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктами 1 и 3 части первой статьи 46, частями первой и пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина Р.З. Камалова на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 4 пункта 1 статьи 6 Закона Республики Татарстан от 29 ноября 2002 года № 24-ЗРТ «О транспортном налоге», поскольку по предмету обращения Конституционным судом Республики Татарстан ранее было вынесено постановление, сохраняющее свою силу, а разрешение поставленного заявителем вопроса неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину Р.З. Камалову и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 26-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 6 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.Җ. Камалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
28 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Р.Җ. Камалов шикаятен алдан өйрәнгәннән соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.Җ. Камалов шикаяте һәм шуңа өстәмә алынды.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмә милекләрендә двигателенең егәрлеге 100 ат көченә кадәрге (73,55 кВтка кадәр) автомобильләр булган I һәм II төркем инвалидларына теркәлгән транспорт чаралары салым салынудан азат ителә дип билгели.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — II төркем инвалиды һәм аның милкендә двигателенең егәрлеге 104,72 ат көченә тигез булган автомобиль бар. Ул Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәтенең 4 номерлы районара инспекциясенә үз автомобиленә ташламалы салым салыну мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткән. Ләкин күрсәтелгән салым органы хатыннан аңлашылганча, әлеге ташлама аңа бирелә алмый, чөнки «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2005 елның 28 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) 6 статьясындагы 1 пункты нигезендә транспорт салымы салынудан милекләрендә двигателенең егәрлеге 100 ат көченә кадәрге автомобильләр булган I һәм II төркем инвалидлары азат ителә. Шуңа бәйле рәвештә гражданин Р.Җ. Камалов дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының аерым нормаларын гамәлдән чыгару һәм мораль зыянны компенсацияләү турында дәгъва белән Казан шәһәре Идел буе район судына мөрәҗәгать иткән, суд үзенең билгеләмәсе белән әлеге дәгъва гаризасын аңа кире кайтарган.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы закон чыгаручысы тарафыннан заманча автомобильләрнең егәрлеге һәм идарә иткәндә иминлекне арттыру өлешендә техник яктан камилләшүе исәпкә алынмаган дип билгели. Дәгъва белдерелә торган нигезләмә, аның фикеренчә, инвалидлык буенча ташламаларга ия булган автоһәвәскәрләрнең имин йөрү өчен югарырак мөмкинлекле заманча автомобильләр алу хокукларын чикли. Ул милекләрендә двигателенең егәрлеге 100 ат көченнән артыграк автомобильләргә ия булган I һәм II төркем инвалидлары транспорт салымын билгеләнгән егәрлектән арткан чикләрдә генә түләргә тиеш һәм бу Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелгән хокукый һәм социаль дәүләт принципларына туры килеп торыр иде дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.Җ. Камалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасын Татарстан Республикасы Конституциясенең 3, 7, 13, 28 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Транспорт салымын түләү буенча ташламаларны кертеп, социаль ярдәм чараларын күрсәтү шартлары һәм тәртибенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул 2014 елның 3 июлендәге 59-П номерлы карарында күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Конституциясе кебек үк, гражданнарның төрле категорияләренә күрсәтелә торган социаль яклауның конкрет төрләрен һәм күләмнәрен билгеләмәгәнгә күрә, республика закон чыгаручысы, транспорт салымы караган региональ салымнарны түләү буенча ташламаларны да кертеп, социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салганда билгеле бер карамак ирегенә ия. I һәм II төркем инвалидларына транспорт салымын түләү буенча ташлама билгеләгәндә, Татарстан Республикасы закон чыгаручысы конкрет транспорт чарасы төре — милекчесе инвалид булган двигатель егәрлеге 100 ат көченә кадәрге (73,55 кВтка кадәр) автомобильдән чыгып аны бирүнең нигезләрен дифференциацияләргә хокуклы булган. Шул ук вакытта транспорт чарасының төре, шулай ук күрсәтелә торган салым ташламасының күләме дәгъва белдерелә торган нормада, сәламәтлеге торышына карап, башка гражданнар белән чагыштырганда өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булган гражданнар категорияләрен дә, республиканың финанс мөмкинлекләрен дә сыйфатлаучы объектив әһәмиятле критерийларны исәпкә алып билгеләнгән. Әлеге җайга салу салым мөнәсәбәтләре өлкәсендәге тигезлек һәм ярашканлык конституциячел принципларына (Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 статьялары) туры килеп тора, чөнки дәгъва белдерелә торган нормада каралган салым ташламасы милекләрендә двигателенең егәрлеге 100 ат көченә кадәрге (73,55 кВтка кадәр) автомобильләр булган I һәм II төркем

инвалидларының барысына да кагыла, шулай ук кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен кире кагу яки киметү максатларын куймый.

Татарстан Республикасы Конституция судының китерелгән хокукый позициясе үз көчендә кала.

Шулай итеп, гражданин Р.Җ. Камалов мөрәҗәгатенең предметы булып аңа карата Татарстан Республикасы Конституция судының үз көчендә калган карары чыгарылган нигезләмә булганга күрә, мөрәҗәгать итүченең шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты нигезендә карауга алына алмый. Транспорт салымы тарифларын үзгәртү турында ул куйган мәсьәләне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 3 пунктларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 статьяларына, 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.Җ. Камалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки элегрәк мөрәҗәгать итү предметы буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклый торган карар чыгарылган, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.Җ. Камаловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 26-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки И.А. Лаптевой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2.1 и 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», а также пунктом 6 Порядка информационного обмена между организациями-участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат»**

28 декабря 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки И.А. Лаптевой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка И.А. Лаптева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2.1 и 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» (далее также — Положение).

Пункт 2.1 Положения устанавливает, что субсидии-льготы предоставляются отдельным категориям граждан, имеющим право на меры социальной поддержки по оплате жилищно-коммунальных услуг, по месту постоянного жительства в соответствии с законодательством. Пунктом 3.1 Положения определена формула для расчета размера субсидии-льготы отдельному члену семьи, имеющему право на указанную субсидию.

От гражданки И.А. Лаптевой поступило также дополнение к жалобе, в котором она ставит вопрос о проверке конституционности пункта 6 Порядка информационного обмена между организациями-участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета

Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат» (далее также — Порядок). Данной нормой предусмотрена последовательность информационного взаимодействия министерств, ведомств и других организаций при предоставлении субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат.

Как следует из жалобы, дополнения к ней, а также приложенных к ним копий документов, заявительница проживает в жилом помещении на основании договора социальной ипотеки и оплачивает коммунальные услуги, связанные с содержанием и обслуживанием жилого помещения, на основании счета-фактуры, в который в соответствии с решением, принятым на общем собрании собственников указанного дома, включена плата за услугу по охране двора в размере 410 рублей в месяц. Заявительница воспитывает сына-инвалида, в связи с чем ей в соответствии с законодательством предоставляется субсидия-льгота на оплату жилищно-коммунальных услуг. Между тем данная субсидия-льгота не включает в себя оплату услуги по охране двора. Гражданка И.А. Лаптева обращалась в Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан с просьбой о предоставлении ей субсидии-льготы на оплату указанной услуги, как входящей в состав жилищно-коммунальных услуг согласно счету-фактуре. Однако из ответа на ее обращение следует, что услуга по охране двора является дополнительной, соответственно предоставление субсидии-льготы на данную услугу будет возможным только в случае включения ее в общее имущество в многоквартирном доме и предоставления управляющей компанией необходимых сведений в органы социальной защиты.

В связи с этим гражданка И.А. Лаптева обратилась к мировому судье судебного участка № 2 по Советскому району города Казани с иском к обществу с ограниченной ответственностью «Управляющая компания “Жилище и Комфорт”» о возложении обязанности произвести перерасчет платежей за жилищно-коммунальные услуги, о компенсации морального вреда и взыскании штрафа, который своим решением отказал в удовлетворении ее исковых требований. Апелляционным определением Советского районного суда города Казани данное решение мирового судьи было оставлено без изменения. Определением судьи Верховного суда Республики Татарстан в передаче кассационной жалобы заявительницы для рассмотрения в судебном заседании кассационной инстанции Верховного суда Республики Татарстан также было отказано.

По мнению заявительницы, обжалуемые нормы Положения нарушают ее конституционные права, поскольку в них не дано четкого и недвусмысленного определения перечня жилищно-коммунальных услуг, за оплату которых предоставляется субсидия-льгота. Она также полагает, что положения пункта 6 Порядка в части, устанавливающей механизм взаимодействия управляющих организаций с уполномоченными органами, рассматривающи-

ми информацию, необходимую для предоставления гражданам жилищно-коммунальных субсидий, исходя из сложившейся практики их применения, позволяют требовать от управляющих организаций предоставления сведений, прямо не предусмотренных указанной нормой, что также приводит к нарушению ее конституционных прав.

На основании изложенного гражданка И.А. Лаптева просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункты 2.1 и 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126, а также пункт 6 Порядка информационного обмена между организациями-участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20, не соответствующими статьям 13 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49, 51, 55 (части первая и вторая), 58 и 60 Конституции Республики Татарстан.

2. Общие правила и принципы порядка формирования платы за жилое помещение и коммунальные услуги, а также перечень услуг, включаемых в структуру указанной платы, закреплены нормами раздела VII Жилищного кодекса Российской Федерации, в частности, его статьей 154 и находящимися с ней во взаимосвязи соответствующими положениями постановлений Правительства Российской Федерации от 3 апреля 2013 года № 290 «О минимальном перечне услуг и работ, необходимых для обеспечения надлежащего содержания общего имущества в многоквартирном доме, и порядке их оказания и выполнения», а также от 13 августа 2006 года № 491 «Об утверждении Правил содержания общего имущества в многоквартирном доме и Правил изменения размера платы за содержание и ремонт жилого помещения в случае оказания услуг и выполнения работ по управлению, содержанию и ремонту общего имущества в многоквартирном доме ненадлежащего качества и (или) с перерывами, превышающими установленную продолжительность».

Оспариваемое Положение принято в рамках реализации части тринадцатой статьи 17 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации», в силу которой инвалидам и семьям, имеющим детей-инвалидов, предоставляется право на компенсацию расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг в размере 50 процентов. Обжалуемые гражданкой И.А. Лаптевой пункты 2.1 и 3.1 Положения направлены на обеспечение права отдельных категорий граждан на получение рассматриваемой субсидии-льготы, по своей правовой природе определяют порядок их обращения за ее получением, а также механизм ее расчета и сами по себе в системе действующего нормативного регулирования не могут предусматривать требования, регламентирующие условия формирования

платы за жилое помещение и коммунальные услуги, в том числе перечень жилищно-коммунальных услуг, за оплату которых предоставляется субсидия-льгота.

Тем самым рассматриваемые нормы Положения не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы в этой части не является допустимой. Разрешение же поставленного заявительницей вопроса о проверке конституционности обжалуемых норм в части содержания в них перечня жилищно-коммунальных услуг, за которые предоставляется субсидия-льгота на оплату таких услуг, фактически означает оценку на соответствие Конституции Республики Татарстан указанных выше норм федерального законодательства, что на основании статьи 3 во взаимосвязи с пунктом 1 части первой статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

Относительно доводов заявительницы о неконституционности оспариваемого пункта 6 Порядка, как допускающего требовать от управляющих организаций предоставления в уполномоченный орган сведений, прямо не предусмотренных данной нормой, необходимо отметить следующее.

В соответствии с пунктом 1 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» меры социальной поддержки по оплате жилищно-коммунальных услуг предоставляются в денежной форме. Исходя из этого Кабинет Министров Республики Татарстан в Порядке предусмотрел последовательность информационного взаимодействия министерств, ведомств и других организаций в целях предоставления всех видов субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг, включая и субсидии-льготы.

Пунктом 6 Порядка определен механизм взаимодействия, в частности, управляющих организаций с территориальными органами Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в муниципальных образованиях и государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)». Так, в силу подпунктов 3 и 8 пункта 6 Порядка к числу сведений, необходимых для передачи управляющей организацией в указанные органы, относятся информация об изменении паспортных данных населения, проживающего в многоквартирных домах (выдача паспорта, регистрация, снятие с регистрации), в течение предыдущего месяца, расчет и сведения о начислениях за фактически оказанные жилищно-коммунальные услуги, услуги антенны, нормативы потребления коммунальных услуг в разрезе персонифицированных социальных счетов, информация о факте неуплаты гражданами

текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги за 2 месяца, а также за 3 и более месяцев подряд, о факте начала погашения образовавшейся задолженности или о заключении и (или) выполнении соглашения о ее погашении, о факте отключения коммунальных услуг, о факте подключения коммунальных услуг. Кроме того, из системного толкования положений подпунктов 3 и 8 пункта 6 с пунктом 3 Порядка следует, что указанный перечень передаваемых файлов, их формат и структура, а также сроки передачи данных должны быть определены в соглашении, заключенном с Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан (его территориальными органами) или с государственным казенным учреждением «Республиканский центр материальной помощи (компенсационных выплат)» (его отделениями).

По своей правовой природе установленный указанными нормами перечень сведений, передаваемых управляющими организациями в орган, принимающий решение о предоставлении гражданам субсидий-льгот, является исчерпывающим и исключает возможность его произвольного истолкования. Сам по себе порядок передачи приведенных документов направлен на оперативное предоставление гражданам жилищно-коммунальных субсидий, на обеспечение единообразия в правоприменительной практике и не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан.

Разрешение же вопроса о законности и обоснованности судебных постановлений, действий и решений должностных лиц правоприменительных органов (на чем фактически настаивает заявительница) не входит в полномочия Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки И.А. Лаптевой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктами 2.1 и 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», а также пунктом 6 Порядка информационного обмена между организациями-участниками системы предоставления субсидий на оплату жилого помещения и комму-

нальных услуг и ежемесячных денежных выплат, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22 января 2005 года № 20 «Об информационном взаимодействии в системе предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг и ежемесячных денежных выплат», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке И.А. Лаптевой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 27-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.1 һәм 3.1 пунктлары, шулай ук «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең 6 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка И.А. Лаптева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
28 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка И.А. Лаптева шикаятен алдан өйрәнгән судья А.А. Хамматова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка И.А. Лаптева «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 2.1 һәм 3.1 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Нигезләмәнең 2.1 пункты ташлама-субсидияләр законнар нигезендә даими яшәү урыны буенча торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм чараларына хокукы булган гражданнарның аерым категорияләренә бирелә дип билгели. Нигезләмәнең 3.1 пункты белән ташлама-субсидия алуга хокуклы аерым гаилә әгъзасына әлеге субсидия зурлыгын исәпли торган формула билгеләнгән.

Гражданка И.А. Лаптевадан шулай ук шикаятькә өстәмә килде, анда ул «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 6 пунктының конституциячеллеген тикшерү турында мәсьәлә куя. Әлеге норма белән торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирелгәндә министрлыклар, ведомстволар һәм башка оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлек итү эзлеклелеге каралган.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән, шулай ук шуларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче торак урында социаль ипотека шартнамәсе нигезендә яши һәм торак урынны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү белән бәйле коммуналь хезмәтләр өчен күрсәтелгән йорт милекчеләренең гомуми җыелышында кабул ителгән карар нигезендә ишегалдын саклау хезмәте өчен аена 410 сум күләмендә түләү кертелгән исәп-фактура буенча түләп бара. Мөрәҗәгать итүче инвалид улын тәрбияли, шуңа күрә аңа законнар нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия бирелә. Шул ук вакытта әлеге ташлама-субсидиягә ишегалдын саклау хезмәте өчен түләү керми. Гражданка И.А. Лаптева аңа күрсәтелгән хезмәткә, исәп-фактура буенча торак-коммуналь хезмәтләр исәбенә керә торган буларак, түләр өчен ташлама-субсидия бирү турындагы сорау белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать иткән. Ләкин мөрәҗәгатенә бирелгән җаваптан аңлашылганча, ишегалдын саклау хезмәте өстәмә хезмәт булып тора, шуңа күрә әлеге хезмәт өчен ташлама-субсидия бирү аны күпфатирлы йорттагы уртак милеккә керткән һәм идарәче компания социаль яклау органнарына тиешле мәгълүматны тапшырган очракта гына мөмкин булачак.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка И.А. Лаптева Казан шәһәре Совет районы буенча 2 номерлы суд участогының җәмәгать судьясына «“Жилище и Комфорт” идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне яңадан исәпләү бурычын йөкләү, мораль зыянны компенсацияләү һәм штрафны түләттерү турында дәгъва белән мөрәҗәгать иткән, судья үзенең карары белән аның дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарткан. Казан шәһәре Совет район судының апелляция билгеләмәсе белән җәмәгать судьясының әлеге карары үзгәрешсез калдырылган. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән мөрәҗәгать итүченең кассация шикаятен Татарстан Республикасы Югары судының кассация инстанциясе утырышында карауга тапшырудан шулай ук баш тартылган.

